КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1255

«Этилен 600» индустриаль паркын
төзү турында

Татарстан Республикасының сәнәгать инфраструктурасы объектлары үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенең Татарстан Республикасы Түбән Кама һәм Тукай муниципаль районнары территориясендә «Этилен 600» индустриаль паркын төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятен «Этилен 600» индустриаль паркының идарә итүче компаниясе буларак билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин